**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 14 август № 595

г. Казань

Тукай муниципаль районында җир кишәрлекләрен бер категориядән икенче категориягә күчерү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының, «Сетевая компания» ААҖнең Тукай муниципаль районында урнашкан, дәүләт милкендә булган 0,1514 гектар гомуми мәйданлы авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җир кишәрлекләрен түбәндәге кадастр саннары белән кадастр паспортларында күрсәтелгән чикләрдә энергетика объектларын урнаштыру максатларында сәнәгать җирләре һәм башка махсус әһәмияттәге җирләр категориясенә күчерү турындагы тәкъдимен кабул итәргә:

| Җир кишәрлегенең кадастр саны | Мәйданы, гектар |
|---|---|
| 16:39:061001:257 | 0,0314 |
| 16:39:061001:239 | 0,0173 |
| 16:39:061001:246 | 0,0213 |
| 16:39:061001:240 | 0,0128 |
| 16:39:061001:243 | 0,0338 |
| 16:39:061001:242 | 0,0348 |
| Барысы | 0,1514. |

2. «Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Федераль кадастр палатасы» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалына, Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә күчемсез мөлкәт дәүләт кадастры документларына һәм Күчемсез мөлкәткә хокукларның һәм алар белән алыш-бирешләрнең бердәм дәүләт реестрына билгеләнгән тәртиптә тиешле үзгәрешләр кертүне тәкъдим итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\595.docx